КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 29 ноябрь г.Казань № 923

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2014 ел, 21 август, 603 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2014 ел, 21 август, 603 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 13 февраль, 87 нче; 2016 ел, 14 июль, 479 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта «Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Төбәк дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыру тәртибендә:

4 пунктта «Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Төбәк дәүләт экология күзәтчелеге куркынычка йөз тоткан якын килүне кулланып, вәкаләтле органнар раслый торган планар, йөкләмәләр нигезендә үткәрелә торган планнан тыш тикшерүләр рәвешендә, оешмалар һәм гражданнар хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен саклап, планлы (рейд) караулар, тикшерүләр рәвешендә, шулай ук юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр белән багланышка керми контрольдә тоту чаралары рәвешендә гамәлгә ашырыла. »;

9 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Тикшерү вәкаләтле орган җитәкчесе приказы яки җитәкче урынбасары боерыгы нигезендә үткәрелә. Тикшерү вәкаләтле орган җитәкчесе приказында, җитәкче урынбасары боерыгында күрсәтелгән вазыйфаи зат яки вазыйфаи затлар тарафыннан гына үткәрелә ала.»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр багланышка керми контрольдә тоту чаралары вәкаләтле органнарның вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан аларның компетенцияләре кысаларында мондый чараларны үткәрүгә вәкаләтле орган җитәкчесе яки җитәкче урынбасары раслаган йөкләмәләр нигезендә үткәрелә.»;

10 пунктных 3 унктчасында «министрның» сүзен «вәкаләтле орган җитәкчесе» сүзләренә алмаштырырга;

13 пунктның дүртенче һәм бишенче абзацларында «министр приказы яки министр урынбасары боерыгы» сүзләрен «вәкаләтле орган җитәкчесе яки җитәкче урынбасары боерыгы» сүзләренә алмаштырырга;

14 пунктның дүртенче абзацында «министр приказы яки вәкаләтле органның министр урынбасары боерыгы» сүзләрен «вәкаләтле орган җитәкчесе яки җитәкче урынбасары боерыгы» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин